

Мордовия Республикасынын атказанган шагыйре Геннадий Сергеевич Гребенцовнын Казанда татар телендә чыккан «Су нинди тостә?» («Какого цвета вода?») китабынын презентациясен А.С.Пушкин исемендәге китапханәнен милли һәм туган якны ойрәнv әдәбияты бvлеге хезмәткәрләре оештырган.
Китап 2025 елда Татарстан китап нәшрияты тарафыннан танылган шагыйрь, язучы, Татарстан һәм Россия Журналистлар берлеге әгъзасы Ленар Миннемоһим улы Шәехов (Ленар Шәех) тарафыннан татарчага тәржемә итеп басылып чыга. Китапка балалар очен хикәяләр кертелгән. Чарада республиканын мәдәният хезмәткәрләре, әдәби, фәнни җәмәгатьчелеге, милли газета-журналлар вәкилләре, Саранск шәһәре рухи-мәдәни vзәк хезмәткәре Абдурахман-хазрәт Сабитов, Саранск һәм Ләмберә районы мәктәбе укучылары, Рима Фатих кызы Байгельдина житәкчелегендә Татар Тавла авылы китапханәсе, vзенен коллективы белән Иркәм Мансур кызы Заликова, Рузаевка районы Татар Пешлә авылы «БИТ21» китапханәсе житәкчесе Леана Наиль кызы Чавкина белән китапханәнен әйдәп баручы белгече Ләйлә Рафаиль кызы Саляева, шагыйрьнен ижатын хормәт итvчеләр катнашты.



Презентация балалар язучысынын ижаты турында «Пушкинка» китапханәчеләре чыгышлары белән башланып китте. Аннары Мордовия Республикасынын атказанган шагыйре Геннадий Сергеевич Гребенцов тамашачыларны биографиясе һәм язучылык эше белән таныштырды. Язучынын ижатын яратучылар чыгышларында авторнын гади, анлаешлы, халыкчан, юмористик телен шигырьләрендә, хикәяләрендә, әкиятләрендә

һәм пьесаларында булуын билгеләп vттеләр.
Презентация зур әдәбият дәресе рәвешендә узды: ул берничә тапкыр «музыкаль тәнәфесләр» белән vрелеп барды. Яна китап чыгуы белән язучыны Мордовия музыка интернат-мәктәбендә белем алучы талантлы яшь баянчы Матвей Матвеев (педагогы А.Н.Гурьянов), Л.П.Кирюков исемендәге Саранск музыка училищесы студент-гитарачылары Арина Самаркина белән Елизавета Раздобарова музыкаль котладылар. Иркәм Мансур кызы Заликова һәм «Ламзурь» халык фольклор-этнография ансамбле катнашучылары башкаруында татар, мордва телләрендә жырлар бик матур янгырады. Шулай ук Саранск шәһәре 11 урта мәктәбе белән Ләмберә районы укучылары анын шигырьләрен рус, әрзә, татар телләрендә сәнгатьле укыдылар. Презентациядә чыгыш ясаучылар Геннадий Сергеевичнын ижаты балаларнын торле сорауларына жавап биреп, аларда әхлакый-этик сыйфатлар, кешеләргә хормәт хисе, хезмәткә мәхәббәт, тыйнаклылык тәрбияләvләрен билгеләп vттеләр.
Чара турында фикерләре белән Ләмберә районы Татар Тавла авылы китапханәсе житәкчесе Рима Фатих кызы Байгельдина уртаклашты. Рима Фатих кызы болай ди:
- Мордовиянен атказанган шагыйре Геннадий Гребенцовнын «Су нинди тостә?» хикәяләр жыентыгы әрзә телендә 
язылган һәм хәзер татар теленә Татарстан язучысы Ленар Шәех тарафыннан тәржемә ителгән. Геннадий Сергеевич - балалар язучысы, анын хикәяләре һәм шигырьләре балалар тарафыннан жинел кабул ителә. Ә презентациягә килгәндә, очрашу бик кызыклы vтте: язучы турында тулы мәгълумат алдык, «Су нинди тостә?» китабы белән якыннан таныштык; рус, татар, мордва телләрендә шигырьләр укыдылар һәм жырлар жырладылар.
Геннадий Сергеевич бу китапны безнен китапханәгә бvләк итте. Әлеге китап vз укучысын табар дип ометләнәбез. Авторга яна басмалар, киләчәктә ижади унышлар, кызыклы темалар һәм сюжетлар телим.
А.С.Пушкин исемендәге китапханәнен милли һәм туган якны ойрәнv әдәбияты бvлеге хезмәткәрләре тарафыннан әзерләнгән Геннадий Сергеевич Гребенцовнын әдәби ижаты һәм тормыш юлы турындагы китап кvргәзмәсе һәм презентациясе кунакларда зур кызыксыну уятты. Балалар китабы бәйрәме якты, тантаналы, музыкальәдәби кичә буларак vтте.

**Наилә НАСЫРОВА**